Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистә Советы

КАРАРЫ

14 декабрь 2023 ел № 103

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымы турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 156 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге икенче өлеше, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлеге Уставының 33 статьясы нигезендә,

Түбән Мактама бистә Советы КАРАР БИРӘ:

1.«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымы турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 156 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Түбән Мактама бистә Советының 2013 елның 24 декабрендәге 169 номерлы, 2014 елның 24 сентябрендәге 200 номерлы, 2014 елның 19 ноябрендәге 211 номерлы, 2015 елның 5 маендагы 239 номерлы, 2020 елның 14 маендагы 184 номерлы, 2020 елның 25 ноябрендәге 8 номерлы, 2023 елның 26 сентябрендәге 94 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган, торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган җир кишәрлекләреннән тыш) яисә эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) 0,3 процент.

1.2. 5 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- физик һәм юридик затлар - сәнәгать (индустриаль, агросәнәгать) парклары һәм сәнәгать технопарклары (алга таба - сәнәгать паркы) урнашкан һәм эшчәнлек алып бара торган җир кишәрлекләре милекчеләре, алар кече һәм урта эшкуарлыкка мөлкәти ярдәм инфраструктурасының аккредитацияләнгән субъектлары реестрына кертелгән «Татарстан

Республикасы кече һәм урта эшкуарлыкка мөлкәти ярдәм инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2014 елның 27 августындагы 616 номерлы карары нигезендә, 1 елга.»;

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Түбән Мактама ш.т.б. һәм Тихоновка авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталына» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 01 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе башлыгына йөкләргә.

Түбән Мактама шәһәр
тибындагы бистәсе башлыгы Р.А.Бәдретдинов